Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы Советы

**КАРАР №IV-6**

Балык Бистәсе штп. 2025елның 22 декабре

Балык Бистәсе муниципаль районы Советының 14.10.2025 №II-6 карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советының социаль сәясәт, сәламәтлек саклау, мәгариф, мәдәният, яшьләр эшләре һәм спорт буенча даими комиссиясе составына үзгәрешләр кертү турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Түбән Тегерлек авыл җирлеге депутаты И. М Әхмәдиевның вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылуга бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советының Балык Бистәсе муниципаль районы Советының 14.10.2025 №II-6 карары белән расланган социаль сәясәт, сәламәтлек саклау, мәгариф, мәдәният, яшьләр эшләре һәм спорт буенча даими комиссиясе составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. комиссия составыннан чыгарырга: Әхмәдиев Илназ Миңнемулла улын;

1.2. комиссия рәисе итеп: Хаҗиев Вәкил Хашим улын - Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Рус Әшнәге авыл җирлегеннән депутатны расларга.;

1.3. комиссия составына комиссия әгъзасы итеп: Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Шетнево - Тулуш авыл җирлегеннән депутат Кашапов Альфред Альберт улын кертергә.

2. Әлеге карарны http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенчә Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында игълан итәргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе
муниципаль районы Башлыгы Р.Р. Ислямов